ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.09.2021 Олы Кайбыч ав. № 390

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлегенең Генераль планы проектын эшләү турында

Территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 23,24 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14,15 статьяларына, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 31 декабрендәге 507-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2018 елның 09 гыйнварындагы 10 номерлы боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлегенең Генераль планы проектын эшли башларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Кайбыч муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (https://kaibici.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Ф.Ш.Әхмәтовка йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров